**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 17 март № 147

г. Казань

«2016 елга Татарстан Республикасы хезмәт базарында киеренкелекне киметүгә юнәлдерелгән халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә өстәмә чараларны тормышка ашыру» дәүләт программасын раслау турында

Татарстан Республикасында халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт сәясәтен тормышка ашыру, хезмәт базарында киеренкелекне киметү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Теркәлгән «2016 елга Татарстан Республикасы хезмәт базарында киеренкелекне киметүгә юнәлдерелгән халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә өстәмә чараларны тормышка ашыру» дәүләт программасын (алга таба – Программа) расларга.

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгын Программаның дәүләт заказчысы – координаторы һәм аның үтәлешен тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыру буенча вәкаләтле орган итеп билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгын Хезмәт һәм эш белән тәэмин ителеш буенча федераль хезмәт белән үзара мөнәсәбәтләрне гамәлгә ашыруга вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимият органы итеп билгеләргә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы А.В.Песошин